ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
КАРАРЫ

12 ноябрь, 2021 ел. № 11

**«**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Уставы,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 24 ноябрь көнне 2021 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында Новая, Новоселов, Молодежная, Солнечная, Придорожная, Луговая, Цветочная, Полевая урамнары, үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 24 ноябрь көнне 2021 елның сәгать 19.00 Новотроицк авылында Березовая, Садовая, Зеленая, Тополиный тыкрыгы, Центральная урамында 23-94 санлы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 25 ноябрь көнне 2021 елның сәгать 18.00 Новотроицк авылында Ленина, Школьная, Овражная, Центральная с д. № 1-22 санлы үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын билгеләргә.
4. 25 ноябрь көнне 2021 елның сәгать 19.00 Новотроицк авылында Челнинская, к-с Тукаевский, к-с Жукова урамнары үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының дуртенче этабын билгеләргә.
5. 25 ноябрь көнне 2021 елның сәгать 20.00 Новотроицк авылында Сармановкая, Юбилейная, Автозаводская, Космонавтов, Энергетиков, Монтажная, Береговая, Ботаническая, Радужная урамнары үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының бишенче этабын билгеләргә.
6. Халык җыенын уздыру өчен Новотроицк авыл яшәүчеләрнең исемлеге аерым бүленә, сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарылырга тиеш.
7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
   «2022 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
   1) Кече архитектура формаларын сатып алу һәм урнаштыру;
   2) Юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу);

3) Электроматериаллар сатып алу, урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;
4) Новотроицк  авылында ясалма юл тигезсезлекләрен урнаштыру буенча эшләр башкару;
5) Новотроицк авылында юл билгеләрен сатып алу һәм урнаштыру;
6) Новотроицк авылында урам күрсәткечләрен сатып алу.
һәм урнаштыру;

«ӘЙЕ»                                                  «ЮК».

8.  Халык җыенын беренче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Сельская урамы, адресы буенча үткәрергә.
9. Халык җыенын икенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Үзәк урамы, чиркәү янында.
10. Халык җыенын өченче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Ленин урамы, күп фатирлы йортлар ишегалдында.
11. Халык җыенын өченче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, парк «Солнечный» ( мәчеть каршында).
12. Халык җыенын дуртенче этабын Татарстан Республикасы, Тукай районы, Новотроицк авыл, Береговая урамы адресы "Пятерочка"кибете янында  үткәрергә.
13. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Новотроицк  авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә.
14. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
15. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Баш
Новотроицк авыл җирлеге башлыгы                                        Ю.М.Рыбакова